**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3213**
**24.06.2022**

Яр Чаллы шәһәре территориясен төзекләндерүгә бәйле җир эшләрен оештыру һәм үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында

Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 24 октябрендәге 20/8 номерлы карары, шәһәр Уставының 41 статьясының 4 өлешендәге 15 пунктчасы, 42 статьясы нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре территориясен төзекләндерүгә бәйле җир эшләрен оештыру һәм үткәрү турында нигезләмәне кушымтада каралганча расларга.
2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуева йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 24 июнендәге
3213 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре территориясен төзекләндерүгә бәйле
җир эшләрен оештыру һәм үткәрү турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Яр Чаллы шәһәре территориясен төзекләндерүгә бәйле җир эшләрен оештыру һәм үткәрү турында нигезләмә (алга таба – нигезләмә) Яр Чаллы шәһәре территориясен төзекләндерүгә бәйле җир эшләрен оештыруга һәм үткәрүгә бердәм таләпләрне билгели.

2. Нигезләмәнең гамәлдә булуы капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау өчен бирелгән җир участокларында башкарыла торган һәм рөхсәт бирелгән эшләргә (вакытлыча киртәләр урнаштыруга һәм төзелеш зонасыннан коммуникация чыгаруга бәйле эшләрдән тыш) кагылмый.

3. Нигезләмәнең таләпләре Яр Чаллы шәһәре территориясен төзекләндерүгә бәйле җир, төзелеш һәм ремонт эшләрен гамәлгә ашыручы (планлаштыручы) барлык оешмалар (оештыру-хокукый формаларына һәм кайсы ведомствога каравына бәйсез рәвештә), шәхси эшмәкәрләр, физик затлар өчен мәҗбүри.

4. Әлеге нигезләмәнең максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

1) җир эшләре – объектларны төзү, реконструкцияләү (капиталь ремонтлау), карап тоту буенча грунт эшкәртүгә, шәһәр территорияләренең төзекләндерүе вакытлыча бозылуга, юл хәрәкәтен вакытлыча чикләүгә яки вакытлыча туктатуга бәйле эшләр һәм алар белән бергә проект-эзләнү, җир төзелеше, шулай ук әзерлек эшләре (шул исәптән төзелеш материалларын һәм конструкцияләрен туплау, машиналар һәм механизмнар, вакытлы биналар һәм корылмалар урнаштыру), авария эшләре;

2) авария-торгызу эшләре – инженерлык коммуникацияләрендә, башка объектларда кешеләр иминлегенә, аларның хокукларына, шулай ук закон тарафыннан саклана торган мәнфәгатьләренә турыдан-туры янаган куркынычны бетерү өчен, кичектергесез рәвештә җир эшләрен башкаруны таләп иткән ремонт-торгызу эшләре.

3) ремонт – объектның төзеклеген һәм эшкә сәләтлелеген (шул исәптән аның эксплуатация характеристикаларын) торгызу буенча кирәк булганда башкарыла торган һәм башкарганда объектның

ышанычлылыгының һәм куркынычсызлыгының конструктив һәм башка характеристикаларына кагылмый торган эшләр;

4) капиталь ремонт – физик тузуга һәм (яки) җимерелүгә бәйле рәвештә объектның аерым конструктив өлешләрен торгызу яисә объектның төп техник-икътисадый күрсәткечләрен үзгәртмичә, аларны эксплуатацияләү күрсәткечләрен яхшырта торган шундый ук яки башка объектларга алмаштыру эшләре;

5) реконструкцияләү – капиталь төзелеш объектларының, аларның өлешләренең параметрларын (биеклекләрне, катлар санын, мәйданнарны, җитештерү куәте күрсәткечләрен, күләмен) һәм инженерлык-техник тәэмин итү сыйфатын үзгәртү;

6) төзелеш – биналар, төзелмәләр, корылмалар (шул исәптән сүтелә торган капиталь төзелеш объектлары урынында) һәм инженерлык челтәрләре төзү;

7) төзелеш мәйданчыгы – төзелеш (реконструкция, капиталь ремонт) чорында төзелеш, реконструкция, капиталь ремонт объектларын урнаштыру, шулай ук төзелеш материалларын һәм конструкцияләрен туплау, машиналар һәм механизмнар, вакытлы биналар һәм корылмалар урнаштыру өчен, билгеләнгән тәртиптә бирелгән җир участогы;

8) грунт эшкәртү – уенты ясау (яртылаш уенты ясау), өем ясау (яртылаш өем ясау), тигезләүче катлам, фильтрлауга каршы мендәр, кире фильтр, дренаж урнаштыру. Грунт эшкәртү, гидромеханизация чараларын файдаланып, механикалаштырылган ысул белән яки кулдан башкарылырга мөмкин;

9) эшләр башкару зонасы – эшләр башкару өчен бүлеп бирелгән, шулай ук эшләрне башкарганда, шул исәптән материалларны, җиһазларны, механизмнарны, көнкүреш шәһәрчекләрен вакытлыча урнаштыру өчен файдаланыла торган территория;

10) яшел утыртмалар зонасы (газон) – табигый һәм ясалма барлыкка килгән агач-куаклык һәм үләнле үсемлекләр белән капланган территория, шул исәптән парклар, бакчалар, скверлар, газоннар;

11) кызыл линияләр – гомуми файдаланудагы территорияләрнең гамәлдәге, планлаштырыла торган (үзгәртелә торган, яңа төзелә торган) чикләрен, электр тапшыру линияләре, элемтә линияләре (шул исәптән линия-кабель корылмалары), үткәргеч торбалар, автомобиль юллары, тимер юл линияләре һәм корылмалары (линия объектлары) урнашкан җир участоклары чикләрен билгели торган линияләр;

12) җир асты инженерлык корылмаларының һәм коммуникацияләренең саклау зонасы – күрсәтелгән корылмаларның һәм коммуникацияләрнең хуҗалары, шулай ук җир асты инженерлык корылмаларының һәм коммуникацияләрнең торышына, аларны карап тотуга һәм эксплуатацияләүгә контрольне һәм күзәтчелекне гамәлгә ашыручы органнар белән килештермичә теләсә кайсы эшчәнлек төрен үткәрү тыела торган чикләрдә, объект категориясенә бәйле рәвештә, чикләре законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә

билгеләнгән инженерлык корылмалары һәм коммуникацияләре буйлап (тирәли) урнашкан территория;

13) янәшә территория – мондый җир участогы барлыкка китерелгән һәм чикләре Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртип нигезендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре билгеләнгән очракта, бина, төзелмә, корылма, җир участогы янәшәсендәге гомуми файдаланудагы территория;

14) юл – транспорт чаралары хәрәкәте өчен җайлаштырылган һәм файдаланыла торган җир полосасы яисә ясалма корылма өслеге. Юл үз эченә бер яки берничә юл өлешен, шулай ук булган очракта, трамвай юлларын, тротуарларны, юл читләрен һәм бүлү полосаларын ала;

15) юл катламы – юлның өслектән, нигездән һәм нигезнең өстәмә катламнарыннан торган конструктив элементы (салкыннан саклый торган, җылылык үткәрми торган, дренажлый торган һ.б.);

16) инженерлык коммуникацияләре – җир асты һәм җир өсте челтәрләре, электр, җылылык, газ, су белән тәэмин итү, ачык һәм ябык канализация трассалары, элемтә, электр транспортының контакт челтәрләре, шулай ук алардагы корылмалар;

17) объект – биналар һәм корылмалар, инженерлык коммуникацияләре, геодезия билгеләре, юллар һәм юл корылмалары, трамвай юллары һәм башка рельслы юллар, төзекләндерүнең башка объектлары, шул исәптән яшел утыртмалар, шәһәр инфраструктурасы элементлары, ваклап сату, реклама, халыкка хезмәт күрсәтү объектлары;

18) өченче категория катлаулылык объектлары – вакытлы, сезонлы яисә ярдәмче билгеләнештәге биналар һәм корылмалар, шул исәптән җәмәгать бәдрәфләре, тиешле төзелмәләре булган спорт мәйданчыклары;

19) ордер – җир һәм төзелеш эшләрен башкаруга хокук бирә торган документ;

20) килештерүче оешмалар – оешмалар, учреждениеләр, шулай ук кызыксынучы затлар – җир участокларының эш башкаруга үз ризалыгын бирүче һәм шартлар куючы хокук ияләре;

21) төзекләндерүне торгызу – төзекләндерүе бозылган урыннарны норматив актларның техник таләпләренә туры килерлек хәлгә китерү; кышкы чорда объектның эшләү мөмкинлеген күздә тоткан төзекләндерүне өлешчә торгызу рөхсәт ителә;

22) объект хуҗасы – объектка милек хокукында, хуҗалык алып бару, оператив идарә хокукында, аренда хокукында (әгәр объект белән идарә итү аренда шартнамәсендә каралган булса), гомерлек мирас итеп биләү хокукында, даими (сроксыз) файдалану хокукында ия булган зат яисә аннан файдалануны, эксплуатацияләүне һәм карап тотуны гамәлгә ашыручы оешма;

23) заказчы – объектның хуҗасы (яки хуҗасы булып торучы) яисә объектларны төзүне, реконструкцияләүне һәм ремонтлауны (капиталь ремонтлауны), шулай ук инженерлык эзләнүләрен башкаруны, объектларны төзү, реконструкцияләү, ремонтлау (капиталь ремонтлау)

өчен проект документациясен әзерләүне тәэмин итә торган җир участогының хуҗасы тарафыннан вәкаләтләнгән юридик яки физик зат;

24) эшләр башкаручы (подрядчы оешма) – территориянең төзекләндерүе бозылуга бәйле җир, төзелеш һәм ремонт эшләрен башкаручы юридик яки физик зат (генподрядчы, субподрядчы);

25) төзелешне оештыру, эшләр башкару проекты – билгеләнгән тәртиптә килештерелгән, текст формасындагы һәм карталар (схемалар) рәвешендәге материалларны үз эченә алган һәм объектны һәм аның өлешләрен төзүне һәм реконструкцияләүне, шулай ук объектны ремонтлауны (капиталь ремонтлауны) тәэмин итү өчен архитектура, конструктив һәм инженерлык-техник чишелешләрне билгели торган проект документациясе.

Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган башка төшенчәләр Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы һәм Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хокукый актларындагы мәгънәләрендә кулланыла.

## 2 бүлек. Ордерсыз башкару тыелган эшләр

5. Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының ордер комиссиясе тарафыннан бирелә торган ордер нигезендә түбәндәге эш төрләре башкарыла:

1) грунтны ачу һәм әзерләү, шул исәптән аның теләсә нинди эш төрләренә планировкасы;

2) транспорт йөри торган өлешнең, тротуарларның, юл читләренең, бүлү полосаларының, яшел утыртмалар зоналарының юл капламын ачу;

3) әлеге нигезләмәнең 3 бүлегендә күрсәтелгәннәрдән тыш, юл эшләренең барлык төрләре;

4) аларны салу ысулына бәйсез рәвештә, инженерлык коммуникацияләрен төзегәндә, реконструкцияләгәндә, ремонтлаганда (капиталь ремонтлаганда) җир эшләрен, шул исәптән төзелеш урыннарыннан инженерлык коммуникацияләрен чыгару буенча җир эшләрен башкару; төзелеш мәйданчыгы аша транзит белән уза торган һәм аның чикләрендә тоташтыру урыннары булган инженерлык коммуникацияләрен төзегәндә, реконструкцияләгәндә, ремонтлаганда (капиталь ремонтлаганда) җир эшләрен башкару; капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау максатлары өчен бирелгән җир участогы чикләреннән читтә, объектны төзү (реконструкцияләү, капиталь ремонтлау) чорында вакытлыча инженерлык коммуникацияләрен урнаштырганда җир эшләре башкару;

5) трамвай юлларын һәм башка рельслы юллар төзегәндә, реконструкцияләгәндә, капиталь ремонтлаганда җир эшләре башкару, шулай ук аларны ремонтлау, әгәр бу аерымланмаган полотнодагы төзекләндерелгән урын бозылуга бәйле булса, яисә ремонтлана торган участокның озынлыгы 12,5 метрдан артканда, аерымланган полотнода ремонт;

6) электр тапшыру линияләре, элемтә, электр транспортының контакт челтәре баганаларын, яктырту баганаларын урнаштыру;

7) шпунт урнаштыру, субайлар сугу (шул исәптән проект-тикшерү эшләре стадиясендә сынау субайлары);

8) инженерлык эзләнүләре вакытында, геодезик билгеләр урнаштырганда җир эшләре башкару;

9) вакытлыча коймалар һәм киртәләр, шул исәптән төзелеш мәйданчыкларының, эшләр башкару зоналарының вакытлыча киртәләрен кую (алмаштыру) һәм урнаштыру (пландагы торышын үзгәртмичә вакытлыча киртәләрне алмаштырудан тыш, алмаштырыла торган киртә Яр Чаллы шәһәренең ордер комиссиясе тарафыннан бирелгән ордер нигезендә урнаштырылган булса,), шулай ук даими коймалар һәм киртәләр урнаштыру һәм алмаштыру;

10) стационар юл киртәләре һәм юл күрсәтү җайланмалары урнаштыру;

11) биналарның һәм корылмаларның фасадларын реконструкцияләгәндә, капиталь һәм агымдагы ремонтлаганда, шулай ук биналарның (корылмаларның) фасадларын тикшергәндә төзелеш басмаларын һәм стационар вышкалар урнаштыру;

12) территорияләрне төзекләндергәндә һәм яшелләндергәндә, шул исәптән агачлар утыртканда (күчереп утыртканда), төзекләндерүе бозылган урыннарны локаль һәм комплекслы торгызганда җир, юл эшләре башкару;

13) вакытлыча файдаланудагы стационар булмаган һәм капиталь булмаган объектлар, күп урынлы бер катлы коллектив гаражлар, ачык автостоянкалар, җәмәгать бәдрәфләре, тиешле төзелмәләре булган спорт мәйданчыклары һәм өченче категория катлаулылыктагы башка объектлар төзегәндә җир эшләре башкару;

14) шәһәр инфраструктурасы элементларын, шул исәптән 0,3 м дан артык тирәнлектә аерым торучы реклама конструкцияләре, шулай ук 0,3 м дан артык тирәнлектә сәүдә, тукталыш һәм башка павильоннар яисә мәйданы 10 кв. м дан артык булган павильоннар урнаштыру;

15) материалларның, конструкцияләрнең, җиһазларның теләсә кайсы төрләрен махсус билгеләнгән урыннардан тыш урнаштыру;

16) авария-торгызу эшләрен башкару.

## 3 бүлек. Ордерсыз башкару рөхсәт ителгән эшләр

6. Эшнең түбәндәге төрләрен башкарганда ордер алу таләп ителми:

1) бер тәүлек эчендә яисә объектны балансга тотучы белән килештерелгән график буенча өслекне торгызып, бер объект чикләрендә юллар, керү юллары, тротуарлар һәм мәйданчыклар өслеген асфальт катламы калынлыгында фрезерлап кисү;

2) өч тәүлек эчендә яисә объектны баланста тотучы белән килештерелгән график буенча өслекне торгызып, бер объект чикләрендә юллар, керү юллары, тротуарлар һәм мәйданчыклар өслеген ремонтлау;

3) юл өслегенең ярыкларын, деформация җөйләрен ямау;

4) юл өслеген эшкәртү;

5) гомуми озынлыгы 100 м дан артмаган участокларда ялгыз торучы борт ташларын күчерү;

6) коеларның, реперларның, газ һәм кабель коверларының капкачларын алмаштыру һәм көйләү;

7) күчеш тибындагы юл өслеген, ныгытылган һәм ныгытылмаган юл читләрен, бүлү полосаларын, җир полотносы сөзәклеген, су үткәргеч кюветларны профилировкалау һәм планлаштыру;

8) юлдагы су үткәргеч корылмалар системасын әлеге корылмаларның эшен кыенлаштыра торган утырмалардан, пычраклардан, чүптән, чит предметлардан чистарту;

9) юл хәрәкәтен оештыруның техник чараларын тышкы ремонтлау, аларның аерым элементларын алмаштыру, тротуарларда һәм яшел утыртмалар зонасында, юл билгеләре өчен 0,3 м га кадәр тирәнлектә, тимер-бетон нигезле баганалар урнаштыру;

10) эшләр башкаруны юл хәрәкәтен чикләмичә үткәрү шартларында күперләрдә, юл үткәргечләрдә, яр буйларында, тоннельләрдә деформация җөйләре элементларын, яктырту баганаларын, парапетларны, кәрниз ташларын, тротуар плитәләрен, сөзәклекләрне һәм конусларны торгызуга яки ремонтлауга бәйле эшләр;

11) яшел утыртмаларны (юкка чыгарылган куаклар урынына утыртуны да кертеп), паркларның, бакчаларның, скверларның җәяүлеләр сукмакларын карап тоту;

12) җир эшләре башкармыйча, мәйданы 10 кв. м булган, шулай ук 0,3 м га кадәр тирәнлектә павильоннар урнаштыру;

13) 0,3 м га кадәр тирәнлектә аерым торучы реклама конструкцияләрен урнаштыру;

14) ремонтлана торган участокның озынлыгы 12,5 метрдан артмаганда, аерымланган полотнода трамвай юлларын һәм башка рельслы юлларны агымдагы ремонтлау

15) 0,3 м га кадәр тирәнлектә бина баскычы фундаментларын (нигезләрен) урнаштыру өчен җир эшләре;

16) җәяүлеләр юлындагы һәм саклагыч киртәләрне, шәһәр пассажир транспортын көтү павильоннарын агымдагы ремонтлау.

## 4 бүлек. Җир эшләрен башкару тәртибе

7. Рөхсәт алганда, җир эшләрен башкара башлаганчы, гариза бирүче түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

1) аларның урнашуы буенча ачыклык кертү максатында, инженерлык коммуникацияләре җир һәм авария эшләрен башкару зонасында уза торган

оешмалар вәкилләрен урынга чакыру. Эксплуатацияләүче оешмаларның җыелу вакыты һәм урыны турында тиешле рәвештә хәбәр ителгән вәкилләре килмәгән очракта, шулай ук вәкил коммуникацияләрнең торышы буенча ачыклык кертүдән баш тарткан очракта, эш башкаручы зат акт төзи һәм алга таба аның өчен билгеле булган коммуникацияләр торышына таянып эш итә;

2) эшләр башкару урыны схемасы нигезендә юл билгеләре урнаштыру;

3) щитлар, су тотыру блоклары, ПВХ челтәр яки челтәрсыман коймалар белән эшләр башкару урынын киртәләү;

4) барлык ишегалларына һәм эш урынына якындагы биналарга керү мөмкинлеге, моның өчен конкрет ситуациягә туры килгән санда һәм урында, траншея аша ике яктан да биеклеге 1,1 м дан ким булмаган, аскы яктан биеклеге 0,15 м тоташтан тышланган һәм түшәмәдән 0,5 м биеклектә өстәмә киртәләүче планкалы, киңлеге 1 м дан да ким булмаган ныклы күперләр, җәяүлеләр өчен күперләр һәм траплар урнаштыра;

5) Гариза бирүченең исеме, элемтә телефоны номерлары һәм эшләрне башкару сроклары күрсәтелгән мәгълүмати табличка урнаштыру;

6) юл полотносын, җәүлеләр өчен юлларны, брусчатка өслекләрне, юл һәм тротуар плитәләрен, бордюр ташын һәм башка мөлкәтне җимерүне Башкарма комитет белән килештерү.

8. Эшләр башкарганда норматив документларның мәҗбүри таләпләре үтәлергә тиеш.

9. Корылма күчәрен һәм коммуникацияләр трассаларын җирлеккә күчерү (эшләрне башлаудан һәм контроль төшерүне башкарудан башлап траншея салуга һәм объектны эксплуатациягә тапшыруга кадәр), ордер сорап мөрәҗәгать итү вакытына кадәр 30 календарь көннән дә артмаган срокта, җир участогының 1:500 масштабында әзерләнгән инженерлык-топография планы нигезендә башкарылган эшләр үткәрүгә проект документациясе нигезендә башкарыла.

10. Юл өслекләрен сүтүдән калган материаллар төрләре буенча өемнәргә тупланырга тиеш һәм траншеядан чыгарылган балчык белән кушылырга, шулай ук урам хәрәкәтенә комачауларга тиеш түгел. Траншеядан чыгарылган грунтны эш барышында Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән урыннарга чыгарырга кирәк.

11. Төзекләндерелгән территорияләрдә җир асты корылмаларын салу өчен траншеялар һәм котлованнар казу түбәндәге таләпләрне үтәп башкарылырга тиеш:

1) эшләр, эшләрне оештыру проекты нигезендә, этаплап башкарыла;

2) траншея киңлеге минималь, җир асты үткәргечләренә техник шартлар һәм СНиП нормасыннан артмаган булырга тиеш;

3) юл капламын ачу траншеядан 20 см га киңрәк итеп башкарыла һәм туры линияле сызыкка ия; сүтелгән асфальт өслек (кителгән өслек) эш көне дәвамында чыгарылырга тиеш, кителгән өслекне бер тәүлектән арткан срокка өеп кую рөхсәт ителми;

4) урамнарда һәм торак төзелеше урыннарында эшләр башкарганда траншеялардан һәм котлованнардан алынган грунт вакытлыча туплау урынына чыгарылырга тиеш;

5) торбаларны, рельсларны, тимер-бетон эшләнмәләрне һәм эшләр башкару өчен кулланыла торган башка материалларны юл өслегенә, газоннарга өйгәндә, алар астына ятма борыс салып калдыру мәҗбүри.

12. Җир эшләрен башкаручы оешма брусчаткадан, юл һәм тротуар плитәләреннән, бордюр ташыннан һәм башка мөлкәттән эшләнгән өслекләрне сүткәндә, материалларның тулысынча сакланышын тәэмин итәргә һәм объектның территориясен (тротуар плитәсе, асфальт түшәмә, бордюрлар, коймалар, кече архитектура формалары) төзекләндерергә тиеш. Материал җитмәү җир эшләрен башкаручы оешма тарафыннан компенсацияләнә.

13. Җир эшләрен башкарганда яшел утыртмаларны юкка чыгару һәм күчереп утырту Башкарма комитет карары белән расланган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

14. Җир эшләрен гамәлдәге җир асты корылмалары (үткәргеч торба, коелар, кабельләр, фундаментлар һ.б.) тирәсендә башкарганда, эшләрне оештыру проектында каралган ераклыктан ким булган араларда экскаваторлар куллану тыела. Мондый очракларда, эшләр бары тик кулдан башкарыла. Җир эшләрен туңган грунтта алып барганда, чөйле җайланмаларны газүткәргечләрдән, басымлы үткәргеч торбалардан, электр кабельләреннән 5 метрдан якын арада һәм башка җир асты коммуникацияләреннән һәм объектлардан 3 метрдан якын арада куллану тыела. Чөйле җайланмаларны торак йортларга якын араларда куллану тыела.

15. Җир асты коммуникацияләрен һәм корылмаларны салу, үзгәртеп кору һәм ремонтлау юлларны һәм тротуарларны төзү, реконструкцияләү, шәһәр территориясен төзекләндерү һәм яшелләндерү эшләре башланганчы башкарылырга тиеш.

Җир асты корылмаларын салу һәм үзгәртеп кору ачык һәм ябык (траншеясез) ысул белән гамәлгә ашырылырга мөмкин. Теге яки бу ысулны куллану максатчанлыгы, җирле шартларны исәпкә алып, проект белән билгеләнергә тиеш.

16. Юкка чыгарыла торган җир асты корылмалары грунттан чыгарылырга тиеш. Аларны чыгару эшләре аеруча күп көч таләп иткәндә яки югары кыйммәткә ия булганда яки башка сәбәпләр буенча алар, корылмаларны яба торган арматураны демонтажлау буенча транспортлау продуктларыннан азат итү, камера һәм коеларны кимендә 1 м тирәнлектә сүтү, корылманың барлык бушлыкларын грунт белән җентекләп тутыру шарты белән, грунтта калдырылырга мөмкин. Кабель линияләренең очлары бөке белән нygытылган, газ һәм продуктүткәргечләр томаланган, мазутүткәргечләр пар белән өрдереп чистартылган һәм томаланган, сүүткәргеч торбалар томаланган булырга тиеш.

17. Җир асты корылмаларын салу, юкка чыгару, ремонтлау яисә реконструкцияләү эшләрен башкарганнан соң, яңа коммуникацияләр салу турындагы мәгълүматлар, шулай ук гамәлдәге коммуникацияләрнең урнашуындагы үзгәрешләр турындагы мәгълүматлар, ордерны япканда 1:500 масштабындагы башкарма сызымнарда чагылдырылырга тиеш.

18. Траншеяларны һәм котлованнарны күмү җир эшләрен башкаруга рөхсәттә күрсәтелгән срокта, асфальт-бетон өслекне торгызуны гамәлгә ашыручы оешма вәкиленең техник күзәтүе астында, рөхсәт биргән органның вәкиле катнашында мәҗбүри рәвештә акт төзеп башкарылырга тиеш. Юлларда һәм тротуарларда траншеяларны һәм котлованнарны күмү, 0,2 м калынлыкта катламлап, тыгызлап һәм су сибеп, комлы грунт белән башкарылырга тиеш (җәйге вакытта). Кышкы вакытта (1 октябрьдән 1 майга кадәр) траншеяларны һәм котлованнарны эреп йомшаган комлы грунт белән тыгызлап күмәргә кирәк.

Гамәлдәге коммуникацияләр белән кисешкән урыннарда траншеяларны күмү әлеге җир асты коммуникацияләрен эксплуатацияләүче оешмалар вәкилләре катнашында башкарыла.

Җир эшләрен башкару өчен җаваплы зат, траншеяларны һәм котлованнарны күмү эшләрен үткәрү алдыннан бер эш көне алдан, коммуналь челтәрләргә хезмәт күрсәтә торган тиешле оешмаларга аларны күмә башлау вакыты турында хәбәр итәргә тиеш.

19. Урамны траншеялар белән кисеп чыкканда, юлдагы борт ташының биеклеген кимендә – 15 сантиметр, ә тротуар ташын асфальт биеклегендә тәэмин итеп, юл өлешендә асфальт-бетон өслекне траншеядан һәр якка – кимендә биш метр, ә тротуарда кимендә өч метр итеп карталар белән торгызырга кирәк.

20. Коммуникацияләрне буйга сузганда тротуарларның, җәяүлеләр өчен юлларның, юлларының асфальт-бетон өслеге бозылган очракта, өслекне борт ташын торгызу буенча тиешле эшләр белән бергә тротуарларның, юлларның, транспорт йөри торган өлешнең бөтен киңлеге буенча торгызырга кирәк.

21. Казылган урынның киңлеге транспорт йөри торган өлешнең 1/3 нән артып китсә һәм транспорт йөри торган өлештә аркылы траншея үткәрелсә һәм казылган урынның киңлеге юлның, урамның, мәйданның тиешле участогының 1/50 нән артса, юлларның, урамнарның, мәйданнарның өслеген, борт ташын торгызу буенча тиешле белән бергә юлларның, урамнарнарның, мәйданнарның бөтен киңлеге буенча торгызырга кирәк.

Җир эшләрен башкару урынында асфальт-бетон өслек сыйфатсыз итеп торгызылган яки биш ел эчендә аның утыруы ачыкланган очракта, аны кабат торгызуны эшләрне башкарган оешма башкара.

22. Килештерелгән һәм расланган проект документлары белән башкасы каралмаган булса, эшләр башкару урынында вакытлыча грунт өемнәре ясарга рөхсәт ителми.

23. Эшләр башкарганда коелар һәм камера люклары капкачларын,

яңгыр суын кабул итү коеларының рәшәткәләрен һәм җиңсәләрен, юл катламы лотокларын, яшел утыртмаларны, геодезия билгеләрен грунт белән күмәргә, шулай ук яшел утыртмалар зонасында, инженерлык коммуникацияләренең саклана торган зоналарында материаллар һәм конструкцияләр өеп куярга рөхсәт ителми.

Ачу эшләре үткәрелә торган урыннарда һәм алар янәшәсендәге территорияләрдә яңгыр һәм кар суларын үткәрүне эшләр башкаручы оешма тәэмин итәргә тиеш. Коеларны, яңгыр кабул итү рәшәткәләрен һәм лотокларны саклау өчен коеларга, яңгыр кабул итү урыннарына һәм лотокларга керү мөмкинлеген тәэмин итүче агач киртәләр һәм тартмалар кулланылырга тиеш.

Инженерлык коммуникацияләре, геодезия билгеләре урнашкан зоналарда мондый объектларның хуҗалары белән килештермичә кире күмүгә яраклы грунтны, шулай ук материалларны вакытлыча өеп куярга тыела.

24. Юлларның транспорт йөри торган өлешләрен һәм тротуарларны төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау буенча эшләр башланганчы, гамәлдәге инженерлык коммуникацияләрен төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау (капиталь ремонтлау) буенча комплекслы төзелеш проектында каралган барлык эшләр дә башкарылырга тиеш.

Юл эшләре башланганчыга кадәр инженерлык коммуникацияләренең комплекслы проектында каралган инженерлык коммуникацияләрен үзгәртеп кору мөмкин булмаса, аларның хуҗалары әлеге коммуникацияләрнең төзелә яки ремонтлана торган юллар һәм тротуарлар белән кисешкән урыннарында юл өслеген ачуны булдырмый торган чараларны үтәргә тиеш.

25. Төзелеш мәйданчыгына керү конструкциясе (пандус) юлның машиналар йөрү өлеше чикләрендә булырга (бордюрның эчке линиясеннән чыгып торырга) тиеш түгел. Төзелеш мәйданына керү үзе каты өслек белән булырга яки юлның машиналар йөрү өлешенә кадәр вак таш түшәлергә тиеш.

## 5 бүлек. Заказчының бурычлары

26. Җир эшләрен башкарганда җир эшләре заказчысы бурычлы:

1) әлеге Нигезләмәнең 2 бүлегендә күрсәтелгән эшләрне башлаганчы, аларны башкаруга ордер рәсмиләштерергә;

2) әлеге Нигезләмәнең 3 бүлегендә күрсәтелгән эшләрне башлаганчы, объектны карап тоту һәм техник эксплуатацияләүне гамәлгә ашыручы оешмага эшләр башлану турында хәбәр итәргә.

27. Заказ бирүче әлеге Нигезләмәнең 2 бүлегендә күрсәтелгән эшләрне башкаруга ордер рәсмиләштерүгә эшләр башкаручыны вәкаләтле итәргә хокуклы.

Эшләр подрядчы оешма тарафыннан башкарылган очракта, заказ бирүче җир эшләрен башкаруга ордерның төп нөсхәсен подрядчы оешмага тапшырырга тиеш

28. Эш башкаручы алмашынган (объект башка оешмага тапшырылган) очракта бер эш көне эчендә ордерны башка хезмәткәргә яки оешмага яңадан рәсмиләштерергә.

29. Шәһәр округының автомобиль юллары буенча хәрәкәтне вакытлыча чикләү яисә туктату Башкарма комитет, Яр Чаллы шәһәре буенча Россия Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ органнары белән килешенеп, заказчылар һәм эш башкаручылар, эш сроклары, урап узу маршрутлары турында барлык кирәкле мәгълүматлар белән мәҗбүри рәвештә юлның ике ягында да мәгълүмат тактасы урнаштырып гамәлгә ашырыла.

30. Заказ бирүче ордерда күрсәтелгән эшләрне башкару срокларын үтәүне контрольдә тотарга тиеш.

Ордерда күрсәтелгән эшләрне билгеләнгән срокта тәмамларга мөмкинлек бирми торган сәбәпләр барлыкка килгән очракта, Заказ бирүче эшләрне башкару срокларын ордерда күрсәтелгән эшләрне башкару срогы чыкканчыга кадәр ике көннән дә соңга калмыйча озайту үтенече белән Яр Чаллы шәһәренең ордер комиссиясенә мөрәҗәгать итәргә тиеш.

31. Заказ бирүче бозылган юл өслеген, яшел үсентеләрне һәм башка төзекләндерү элементларын үз акчалары хисабына торгызу өчен җаваплы.

32. Торгызу эшләрен башкарганда заказ бирүче, билгеләнгән срок эчендә (биш ел) утырулар һәм деформацияләр барлыкка килгән очракта, объектны муниципаль ихтыяҗлар өчен файдалануга кайтару турындагы актка кул куелганнан соң, торгызу эшләрен башкаруның гарантия срогын тәэмин итә.

Башкарылган эшләрне һәм төзекләндерү эшләрен кабул итү Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының район хакимияте вәкилләре, заказ бирүче һәм эш башкаручы тарафыннан имзаланган акт белән тулы күләмдә рәсмиләштерелә.

33. Заказ бирүче ордерда күрсәтелгән эш срогы чыккан көннән башлап өч эш көне эчендә тышкы төзекләндерү элементларын бозу белән бәйле эшләрне башкарганнан соң төзекләндерү эшләрен һәм эшләрне кабул итү актын имзалап объектны тапшырырга тиеш.

34. Эшләр кышкы чорда (1 октябрьдән 1 майга кадәр) башкарылган очракта, Заказчы, ордерда күрсәтелгән эш срогы чыккан көннән башлап өч көн эчендә, җимерелгән төзекләндерү элементларын һәм юлларны торгызу буенча эшләрне арадаш кабул итү актын рәсмиләштерергә тиеш.

Җимерелгән төзекләндерү элементларын һәм юлларны ахыргы торгызу әлеге Нигезләмәнең 54 пунктында билгеләнгән тәртиптә башкарыла һәм җимерелгән төзекләндерү элементларын һәм юлларның ахыргы торгызу эшләре тәмамланганнан соң өч эш көне эчендә кабул итү акты белән тапшырыла.

35. Элек алынган ордер буенча җир эшләрен башкарганнан соң бозылган урыннарны торгызу буенча йөкләмәләрне үтәмәгән очракта яисә заказчы, подрядчы (эшләр башкаручы) системалы рәвештә (ике тапкыр рәттән) производство кагыйдәләрен һәм срокларын үтәмәгән очракта, заказ бирүчегә җир эшләрен башкаруга рөхсәт бирүдән баш тартыла.

36. Эш барышында проект карарларына төзәтмәләр керткән очракта Заказ бирүче төзәтелгән, килештерелгән проект документларын биреп, ордерга тиешле үзгәрешләр кертергә тиеш.

Гамәлдәге ордерга үзгәрешләр һәм өстәмәләр бары тик аны бирү урыны буенча гына кертелә.

## 6 бүлек. Эшләр башкаручының бурычлары

37. Эшләр ордер алган оешма (заказчы) яки ордерда күрсәтелгән подрядчы һәм субподрядчы оешмалар тарафыннан башкарыла ала.

38. Эшләр башкаручы бурычлы:

1) объектта ордерның, аның чикләрендә эшләр башкарыла торган җир участогына хокук билгели торган документның төп нөсхәләре, расланган проект документлары, шулай ук Яр Чаллы шәһәре автомобиль юллары буйлап транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләгәндә (вакытлыча туктатканда) Яр Чаллы шәһәре автомобиль юллары буйлап транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү (вакытлыча туктату) турында Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты боерыгы булырга тиеш һәм ул аларны эшләр башкаруны контрольдә тотучы оешмалар вәкилләренә, шул исәптән Яр Чаллы шәһәре ордер комиссиясе хезмәткәрләренә күрсәтергә;

2) юл хәрәкәтен оештыру схемасы нигезендә юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итәргә;

3) эшләр башкару зонасында булган барлык вакытлы билгеләрнең, шулай ук юл хәрәкәтен җайга салуның техник чараларының төзек хәлдә саклануын һәм аларны карап торуны тәэмин итәргә;

4) төзелеш мәйданчыгын (җитештерү зонасын) шәһәр урамнары белән тоташтыручы вакытлыча керү-чыгу урыннарын урнаштыру кирәк булганда, аларны каты өслек һәм автомойка белән җиһазландырырга;

5) эшләр башкаруны контрольдә тотучы органнар вәкилләренә, шул исәптән Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының Административ-техник инспекция идарәсе хезмәткәрләренә төзелеш мәйданчыгына (эшләр башкару зонасына) керү мөмкинлеген тәэмин итәргә;

6) эшләрне үткәрү урынын оешманың исемен, телефон номерын һәм эш башкаручының фамилиясен күрсәтеп, казу урынының бөтен периметры буенча бер типтагы коймалар белән әйләндереп алырга (кичке һәм төнге вакытларда урамнарның, мәйданнарның, юлларның йөрү өлешендәге казылган урыннардагы коймаларда өстәмә рәвештә яктырту булырга тиеш);

7) җәяүлеләр хәрәкәтен урамның ике ягы буенча да 1,5 м киңлектәге тротуар өчен полосалар калырлык итеп оештырырга, шул ук вакытта алар бөтен киңлек буенча койма белән әйләндерелергә тиеш;

8) траншея һәм җәяүлеләр күперләре аша чыгу юлларын урнаштыру юлы белән ишегалларына (комплексларга) һәм корылмаларга керү юлларын тәэмин итәргә (кышкы вакытта алар даими рәвештә кардан һәм боздан чистартылырга, ком сибелергә тиеш);

9) ордерны рәсмиләштергәндә, килештерүче оешмалар тарафыннан килештерелгән проект (төзелеш, эшләр башкару оешмасының) нигезендә, техниканы вакытлыча саклауны һәм көнкүреш шәһәрчеген урнаштыруны оештырырга, мондый Материалларны, техниканы эш урынына китерүне, ордерда күрсәтелгән оешмаларда ордер теркәлгәннән һәм гамәлдәге объектларның сак зоналарына рөхсәт алганнан соң гына башкарырга (кирәк булганда, вакытлыча гамәлдәге объектларның сак зоналарындагы территорияне алырга);

10) төзелеш мәйданчыгын (эшләр башкару зонасын) һәм якын-тирә территорияне Яр Чаллы шәһәренең төзекләндерү кагыйдәләре нигезендә тиешле хәлдә тотарга;

11) төзелеш мәйданчыгы территориясендә каты көнкүреш калдыклары, эре габаритлы һәм төзелеш чүп-чары, шулай ук башка җитештерү һәм куллану калдыклары җыю өчен контейнерлар һәм (яки) чүп җыю бункерлары булуны тәэмин итәргә.

12) төзелеш мәйданчыгы территориясеннән каты көнкүреш калдыклары, эре габаритлы һәм төзелеш чүп-чарын, шулай ук җитештерү һәм куллану калдыкларын билгеләнгән тәртиптә чыгаруны оештыруны тәэмин итәргә;

13) автотранспорт (төзелеш машиналары) көпчәкләре белән төзелеш мәйданчыгы территориясенннән (эш зоналарыннан) читкә пычрак чыгармаска;

14) ордер шартларын үтәргә, шул исәптән топосъемкада күрсәтелгән эшләрне башкару зонасы чикләрен үтәү буенча, шулай ук эшләрне башкару срогы буенча (яраклылык срогы чыккан ордер буенча эшләү ордерсыз эшләүгә тиңләштерелә);

15) тиешле оешмаларга траншеялар һәм котлованнарны күмә башлау вакыты турында үз вакытында хәбәр итәргә, гамәлдәге коммуникацияләр белән кисешкән урыннарда траншеяларны күмү әлеге җир асты коммуникацияләрен эксплуатацияләүче оешмалар вәкилләре катнашында башкарыла;

16) Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты боерыгы нигезендә Яр Чаллы шәһәре автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү (вакытлыча туктату) тәртибен һәм срокларын сакларга (мондый чикләүләр кертелгән очракта);

17) юл хәрәкәтен оештыруның гамәлдәге схемасын вакытлыча бозган эшләр тәмамланганнан соң, әгәр проектта башкасы каралмаган булса, юл

хәрәкәтен җайга салуның техник чараларының даими дислокациясен тулысынча торгызырга;

18) казылган урында җимерелгән газоннарны, яшел үсентеләрне, борт ташын һәм асфальт-бетон катламын сыйфатлы итеп һәм казылган урында хәрәкәт итү өлешенең яки тротуарның бөтен киңлегенә торгызырга.

19) төп эшләр тәмамланганнан соң, төзекләндерүе бозылган урыннарны торгызырга һәм материалларны, конструкцияләрне, төзелеш чүп-чарын, торгызу эшләреннән соң коймаларны җыеп алырга һәм ордерда күрсәтелгән вакытта билгеләнгән тәртиптә ордерны ябарга.

## 7 бүлек. Авария-торгызу эшләрен башкару тәртибе

39. Инженерлык коммуникацияләре хуҗалары аларга караган коммуникацияләрдә авария турында сигнал алганда, кичекмәстән авария бригадасын җибәрергә тиеш, ул җаваплы зат җитәкчелегендә юл хәрәкәте иминлеген, якын-тирәдә урнашкан инженерлык коммуникацияләрен һәм башка объектларның сакланышын тәэмин итеп, аварияне бетерүгә керешергә тиеш.

40. Эксплуатацияләгәндә яки төзелеш эшләре башкарганда инженерлык коммуникацияләрендә һәм корылмаларда булган аварияләрне бетерү максатларында андагы авария-торгызу эшләрен (шул исәптән казуны) эшләр башкару урынының төгәл географик (адрес) урыны күрсәтелгән телефонограмма буенча башларга кирәк, ул объектның хуҗасы тарафыннан Яр Чаллы шәһәренең ордер комиссиясенә җибәрелә.

Телефонограмма җибәрү белән бер үк вакытта, аварияне бетерүче оешма бер эш көне эчендә Яр Чаллы шәһәре ордер комиссиясендә авария эшләрен башкаруга ордер рәсмиләштерергә тиеш.

41. Телефонограмма алганда авария зонасында җир асты коммуникацияләре булган оешмалар авария булган урынга, үз ведомствосындагы коммуникацияләрнең (корылмаларның) җирлектә урнашкан урынын ачыклау һәм эш ысулын килештерү өчен башкарма сызымнар белән кичекмәстән вәкил җибәрергә тиеш.

Транспорт йөри торган өлештә авария эшләрен башкару тәртибен Яр Чаллы шәһәре буенча Россия Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ органнары белән килештерергә кирәк.

Аварияне бетерү эшләре юлны тулысынча яки өлешчә ябуны таләп итсә, Россия Эчке эшләр министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча ЮХИДИ идарәсе органнары шәһәр Башкарма комитеты белән берлектә юлны вакытлыча ябу, транспортның урау маршруты һәм зыянны бетерүнең (кызыксынган эксплуатация оешмалары белән берлектә) иң кыска срогын билгеләү турында оператив карар кабул итәләр.

42. Аварияне бетерү буенча эшләр урынында даими рәвештә хезмәт таныклыгы һәм Яр Чаллы шәһәре ордер комиссиясе тарафыннан бирелгән

ордеры булган, оешманың авария эшләрен башкаручы җаваплы вәкиле булырга тиеш.

43. Коммуникациянең (корылмаларның) тибына карамастан, авария чокырлары урыннарындагы аварияләрне, төзекләндерүне тулысынча башкарып, өч көнлек срокта бетерергә кирәк.

44. Аварияне бетереп, траншеяларны (котлованны) күмеп, чүп-чарны җыештырганнан соң, эшләрне башкаручы оешма җимерелгән урыннарны торгызырга, ел фасылына карамастан, транспорт йөри торган өлешне һәм тротуарларны торгызу (автотранспортның аварияcез хәрәкәтен тәэмин итү һәм механикалаштырылган җыештыру өчен) буенча эшләрне өч календарь көн эчендә башкарырга тиеш.

45. Эшләрне кышкы чорда (1 октябрьдән 1 майга кадәр) башкарганда, кече архитектура формаларын, яшел үсентеләрне яңадан торгызу мөмкинлеге булмаганда һәм асфальт өслеген яңадан ясау зарурлыгы булганда, эш башкаручы төзекләндерү эшләрен 1 майдан 31 майга кадәр башкарырга тиеш.

46. Авария-торгызу эшләрен үткәрү объекты төзекләндерү һәм юл-ремонт эшләренең факттагы үтәлешен һәм аларның сыйфатын тикшергәннән соң контрольдән төшерелә, бу хакта эш башкаручы оешма вәкилләре, территорияне үз балансында тотучы, Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының район (районнар) хакимиятләре, шулай ук ЭЭМ Идарәсенең Яр Чаллы шәһәре буенча ЮХИДИ органнары вәкилләре (әгәр юл эшләре башкарылса) катнашында акт төзелә.

47. Авария-торгызу эшләрен башкару зонасын төзекләндерү эшләрен авария-торгызу эшләрен башкаруга ордерда күрсәтелгән срокларда башкару мөмкин булмаса, әлеге эшләрне башкаруга Яр Чаллы шәһәре ордер комиссиясендә даими ордер рәсмиләштерергә кирәк. Срогы чыккан ордер буенча эшләр ордерсыз эшләргә тиңләштерелә.

48. Авария-торгызу эшләре дип планлы эшләр башкару тыела.

49. Трассаның гомуми озынлыгы (траншеялар) 10 м дан артык булган инженер коммуникацияләрендә авария эшләрен башкару зарурлыгы булганда, эшләр башкаруга ордер планлы эшләр башкаруга ордер рәсмиләштерү өчен каралган тәртиптә рәсмиләштерелә.

## 8 бүлек. Төзекләндерүе бозылган урыннарны торгызу

50. Объектларны төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау (капиталь ремонтлау) буенча эшләр башкарганнан соң заказчы (эшләр башкаручы оешма) Яр Чаллы шәһәре ордер комиссиясе тарафыннан бирелгән ордерда күрсәтелгән срокларда төзекләндерүе бозылган урыннарны торгызу эшләрен башкарырга тиеш.

51. Траншея (котлован) күмелгәннән соң, урамнарның аркылы чыга торган урыннарында һәм трамвай һәм башка рельс юллары чикләрендә казылган юл полотносын торгызу эшләре кичекмәстән башланырга һәм

күмелгән вакыттан башлап 24 сәгать эчендә төгәлләнергә тиеш, ә калган барлык очракларда - өч тәүлек эчендә башкарылырга тиеш.

52. Траншеяны (котлованны) күмү эшләрен башкаручы оешма объектны юл капламын яки тышкы төзекләндерү элементларын (яшел утыртмалар, катламлы юллар һәм мәйданчыклар, кече архитектура формалары һ. б.) торгызучы оешмага тапшырырга тиеш:

1) төзелеш калдыклары белән эш итү буенча технологик регламент нигезендә объекттан калган материалларны, артып калган грунтны, төзелеш чүп-чарын чыгару;

2) кабул итү-тапшыру акты буенча торгызыла торган территория хуҗасының җаваплы вәкиле һәм эшләр башкаручы катнашында объектны торгызу өчен тапшыру. Ремонт эшләрен башкару чикләреннән читтәге эшләр барышында юл катламына механик зыян килгән очракта, торгызу күләме объектны карап тоту һәм техник эксплуатацияләү белән шөгыльләнүче оешма вәкиле катнашында зыян күрү актын төзеп, комиссия тарафыннан билгеләнә.

53. Юлларда һәм тротуарларда траншеяларны (котлованнарны) торгызу срокларын үтәүгә Яр Чаллы шәһәренең ордер комиссиясе контрольлек итә.

Эшләр кышкы чорда (1 октябрьдән 1 майга кадәр) башкарылган очракта, траншеяларны күмгәннән соң асфальт-бетон өслек урынына автотранспорт каршылыксыз узсын һәм җәяүлеләр йөри алсын өчен юл плитәләреннән яки данәле материаллардан вакытлы юл өслеге ясала.

54. Тулысынча төзекләндерү эшләре 1 майдан 31 майга кадәр гамәлгә ашырыла.

Асфальт-бетон катламнарны технологик эзлеклелектә торгызу тышкы һава температурасы көз көне 10°С һәм яз көне 5°С түбән булмаганда башкарылырга тиеш.

55. Яшел зонаны торгызуны казылган өске катламны бары тик үсемлек грунты (кар һәм боздан башка) белән генә торгызуны исәпкә алып башкарырга кирәк. Аны түшәгән урыннарда үсемлек грунтының (кара балчыкның) калынлыгы 5 см дан да ким булмаска тиеш. Яшел зонаны планлаштыру төгәл горизонталь һәм вертикаль буенча башкарылырга һәм аңа үлән чәчелергә тиеш.

56. Эшләр урынында эшләр тәмамланганнан соң биш ел эчендә утырулар барлыкка килгән очракта, заказчы аларны бетерүне тәэмин итәргә тиеш.

## 9 бүлек. Җир эшләрен башкарганда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү

57. Эшләрне башкаручы килешенгән тәртипне, эшләрнең чиратлылыгын тәэмин итәргә, аларны башкару срокларын үтәргә, юл хәрәкәте иминлеген оештырырга тиеш.

58. Транспорт йөри торган өлештә, тротуарларда, юл кырыйларында, бүлү полосаларында, урам газоннарында эш тәртибе һәм вакыты әлеге эшләр чорында юл хәрәкәтен оештыру схемасы белән билгеләнә. Әлеге таләп авария-торгызу эшләрен башкаруга кагылмый.

59. Юл хәрәкәтен оештыру схемасы проект документлары составында эшләнергә тиеш. Әлеге таләп авария-торгызу эшләрен башкаруга кагылмый.

60. Эшләр башкару урыны щит-заставкалар (вакытлы юл бүлгечләре белән су салу блоклары) белән тәэмин ителә. Урамнарның (магистральләрнең) транспорт йөри торган өлешендә, коймадан тыш, кызыл габарит фонарьлары, юл билгеләре, транспорт, җәяүлеләр йөрү күрсәткечләре һ. б. урнаштырыла.

Җәяүлеләр хәрәкәте зоналарындагы эш урыннары тышкы яктырту булмаганда яктырткычлар белән җиһазландырыла.

61. Эшләр алар җитәкчелегендә башкарыла торган вазыйфаи затлар коймаларның булуы һәм аларның торышы, яктырту һәм габарит фонарьларының эшләве, юл билгеләренең һәм күрсәткечләренең эшләрне тулысынча тәмамлаганга кадәр сакланышы өчен җаваплы.

62. Эшләр башкарганда биналар янына ирекле керү һәм аларга траншеялар (эшләр башкару зонасы) аша култыксалы җәяүлеләр күперләрен урнаштыру юлы белән керү, шулай ук эш тәртибе нигезендә ишегалларына ирекле керү тәэмин ителергә тиеш.

63. Расланган (төзелеш, эшләр башкаруны оештыру) проект нигезендә эшләр зонасын тулысынча әзерләгәнче эшләрне башларга, объектта механизмнар, техника, материаллар, инвентарьлар, көнкүреш вагоннары урнаштырырга ярамый. Әлеге таләп авария-торгызу эшләрен башкаруга кагылмый.

64. Җәяүлеләр өчен куркынычсыз хәрәкәт тәэмин итү максатларында урамның ике ягыннан да киңлеге 1,5 метрдан ким булмаган юл булдыру күздә тотыла. Аерым очракларда тротуар тулысынча ябылырга мөмкин, ләкин шул ук вакытта каршы як тротуар буенча җәяүлеләр кичүен оештырып җәяүлеләр хәрәкәте мәҗбүри рәвештә сакланырга тиеш.

65. Җитештерү зонасы җәяүлеләр зонасына якын урнашкан урыннарда җәяүлеләрнең иминлеген тәэмин итү максатыннан, койма өстендә саклагыч түбә, ә тротуарда - җәяүлеләр өчен транспорт хәрәкәте ягыннан култыксалар белән җиһазландырылган түшәмә куела.

66. Инвентарь коймалар гамәлдәге дәүләт стандартлары таләпләренә җавап бирергә тиеш.

67. Урамнарның машиналар йөрү өлешендә эшләгәндә, койма сыйфатында моның өчен махсус билгеләнгән полимер материаллардан блоклар кулланылырга мөмкин. Эшләр башкару зонасының коймасы сыйфатында бетон блоклар һәм тимер-бетон субайлар куллану тыела.

68. Җитештерү зонасы коймаларын куйганда (урнаштырганда) эшләр башкаручы аның өчен мәҗбүри булган «Төзелеш мәйданчыкларын һәм төзелеш-монтаж эшләрен башкару участокларының инвентарь коймалары.

Техник шартлар» ГОСТ Р 58967-20 таләпләрен үтәргә тиеш. Эш зонасы коймаларының тышкы күренеше пөхтә булырга тиеш: буялган, пычрактан чистартылган, юылган, аларда уемнар, зыян күргән участоклар, вертикальдән читкә тайпылышлар, чит наклейкалар, белдерүләр, язулар булырга тиеш түгел.

69. Эшләр башкаручы траншеялар аша җәяүлеләр корылмаларын тиешенчә карап тотуны тәэмин итәргә бурычлы.

70. Урамнарның машиналар йөрү өлешендә һәм тротуарларда эшләрне башкаручы юл хәрәкәте иминлегенең кирәкле техник чаралары белән тәэмин ителгән булырга тиеш: яхшыртылган ут-техник характеристикалары булган юл билгеләре, импульслы сигнал уклары, фонарьлар, юл эшчеләре өчен яктылыкны кире кайтаручы махсус униформа һәм юл техникасы өчен кызгылт-сары төстәге ялтыравык маяклар. Юл хәрәкәте иминлегенең техник чараларын урнаштыру билгеләнгән таләпләр нигезендә башкарыла. Күрсәтелгән чаралар булмаса, машиналар йөрү өлешендә эшне башлау тыела.

71. Автомобиль транспорты һәм җәяүлеләр хәрәкәте урыннарында кое капкачларын ачу зарурлыгы булганда, люклар койма белән тотып алына, сигнализация чаралары һәм урап узу юнәлешен күрсәткән вакытлыча кисәтү билгеләре белән җиһазландырыла.

## 10 бүлек. Нигезләмә таләпләрен бозган өчен җаваплылык

72. Нигезләмә таләпләрен үтәмәгән яки бозган өчен заказчы һәм эшләр башкаручы гамәлдәге законнар нигезендә тигез дәрәҗәдә җаваплы.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева